КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 ноябрь г.Казань № 955

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 31 октябрь, 977 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 31 октябрь, 977 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 18 июнь, 480 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль учреждение ачу, яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль учреждениенең штат санын арттыру һәм (яки) яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль учреждениегә мөлкәтне оператив идарә итү хокукында беркетү;»;

8 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ni – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждение ачуга, балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждениенең штат санын арттыруга һәм (яки) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждениегә мөлкәтне оператив идарә итү хокукында беркетүгә, мөлкәтне балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждениегә арендага бирү яки аннан түләүсез файдалану шартнамәләре буенча тапшыруга бәйле рәвештә, балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль биремнең үтәлешен финанс белән тәэмин итү күләмен арттыруга чыгымнар;»;

$8^1$ пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$8^1$. Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждение ачуга, балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждениенең штат санын арттыруга һәм (яки) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждениегә мөлкәтне оператив идарә итү хокукында беркетүгә, мөлкәтне балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждениегә арендага бирү яки аннан түләүсез файдалану шартнамәләре буенча тапшыруга бәйле рәвештә, балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль биремнең үтәлешен финанс белән тәэмин итү күләмен арттыруга чыгымнар ($N_i$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин